УДК 94(47) DOI: 10.22378/he.2019-4-2.274-283

# Г. ӘХМӘРОВНЫҢ «ТӨРКИ ӘЛИФБАСЫ» БИТЛӘРЕНДӘ БАЛАЛАРГА ӘХЛАКЫЙ ТӘРБИЯ БИРҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

***Д.М. Галиуллина***

*Казан федераль университеты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*galiullinadm@mail.ru*

Мәкаләдә мөгаллим Г. Әхмәровның «Төрки әлифбасы» тарихи чыганак буларак, татар халкының балаларны укыту системасы белән бәйле рәвештә анализлана. Әлифбадагы текстлар балаларга әхлакый тәрбия бирү мәсьәләсеннән чыгып тикшерелә. Шулай ук «Әлифба каитапларына тәнкыйть» методик кулланмасына да игътибар бирелә. Тәнкыйтьтә Г. Әхмәров Х. Зәбири, Ш. Таһири, Г. Мөслимов һ.б. әлифбаларны анализлый. Тәнкыйтен мәктәпләрдә иң күп таралган Һ. Максудиның «Мөгаллим әүвәл» әлифбасыннан башлый. Шуңа күрә мәкаләдә бу әлифбага аеруча зур ихтибар бирелә, Г. Әхмәровның «Төрки әлифбасы» басылып чыккач, ике бөек шәхес арасында 1910 елда кызып киткән дискуссия дә искә алына. Бәхәс «Йолдыз» газетасы битләрендә чагылыш таба. Һ. Максудиның «Мөгаллим әүвәл» белән Г. Әхмәровның «Төрки әлифба»сындагы текстларның эчтәлеге чагыштырылып анализлана. Бу уку әсбаплары эчтәлеге ягыннан бер берсеннән нык аерылып тора. Г. Әхмәров кыска эчтәлекле, дөньяви текстларга өстенлек бирә, Һ. Максудиның «Мөгаллим әүвәл»ендә зур күләмле кызык эчтәлекле текстлар күбрәк очрый. Дини тематикага язылганнары да бар. Ләкин авторларның максатлары бер – балаларны ана телендә укырга һәм язарга өйрәтү. Әлифбалар бу бурычны уңышлы үтиләр. 1917 елгы октябрь инкыйлабына кадәр бу уку әсбаплары мәктәпләрдә кулланыла.

**Ачкыч сүзләр:** «Төрки әлифба», «Йолдыз», «Мөгаллим әүвәл», мәдәният, тарих, чыганак, җәдитчелек, әхлак, тәрбия.

**Цитата өчен:** Галиуллина Д.М. Г. Әхмәровның «Төрки әлифбасы» битләрендә балаларга әхлакый тәрбия бирү мәсьәләләре // Историческая этнология. 2019. Т. 4, № 2. С. 274–283. DOI: 10.22378/he.2019-4-2.274-283

Татар милли педагогикасы тарихында тирән эз калдырган шәхесләр аз түгел, ләкин Г. Әхмәровның эшчәнлеге аеруча ихтирамга лаек. Ул татар халкының киләчәге өчен борчылып яшәгән ихлас милли рухлы шәхес. Бу чордагы башка милли интеллигенция вәкилләре кебек үк, милләтне саклап

калу ысулын ул нәкъ белем бирү, балаларны укыту системасын үзгәртүдә күргән. Г. Әхмәров – күп кенә дәреслекләр авторы. Казандагы татар укытучылар мәктәбен (Казанская татарская учительская школа) тәмамлаганга, мәктәптә мөгаллим булып эшләгәнгә, аны бигрәк тә балаларны укырга, язарга өйрәтү методикасы кызыксындыра [10, 14 б]. Нәтиҗәдә татар әлифбаларына багышланган методик кулланма «Әлифба китапларына тәнкыйть» (1909) басылап чыга [3].

1890 еллардан башлап 1917 елга кадәр Казанда 60 ка якын татар әлифбасы дөнья күрә [1, б. 51]. Күпчелеге 1905 елдан соң гына басыла, чөнки мәдрәсәләрдә төп реформа үткәрү нәкъ менә шул чорда башланып китә. Әлифбаларның авторларына килгәндә, алар күбесе мәртәбәле җәмәгать эшлеклеләре, педагоглар – Г. Баруди, Һ. Максуди, Ш. Таһири һ.б. Алар төзегән әлифбалар бик төрле һәм бер-берсеннән нык аерылып торалар. Г. Әхмәров мәктәпләрдә кулланышта булган 15 әлифбаны тикшереп карый, анализ өчен киң таралган 10 дәреслекне генә сайлап ала. Аның фикеренчә, аларның күбесе педагогик норма һәм стандартларга туры килми. Шулай ук ул халык арасында йөргән имеш-мимешләрне дә игътибарсыз калдырмый: күп кенә начар сыйфатлы әлифбаларның мәдрәсә шәкертләре, хәтта печән базарында приказчик хезмәтен үтәүчеләр тарафыннан язылып, соңрак байларның бу китапларны зәкәт буларак ысул җәдит мәктәпләренә таратуларын искәртә. «Ишетдекемезә күрә – Казанда бәгъзе китапчыларның матбагаларында хәреф җыючы шәкертләр дә дәрес китаплары язып яталар имеш, шуларны хуҗалары арзан бәһагә алып бастырып дөньяга тараталар диләр», – дип тә өсти автор. Кайсы әлифбалар турында сүз барганын Г. Әхмәров төгәл язмый. Шулар арасыннан 3–4 генә мәктәпләрдә кулланырга ярый дип саный, калган басмаларда грамматик хаталар, стилистик яктан дөрес булмаган конструкцияләр, балаларга аңлаешсыз текстлар булуын ассызыклый Педагогикадагы иске һәм яңа ысулларны белмичә мәктәп балалалары өчен әлифба язуны «дуга белән печән чабу» белән тиңли [3, 2–3 б.]

Автор – аваз методы тарафдары, шуңа күрә ул иҗек методына нигезләнгән күп кенә әлифбаларны тәнкыйтьли. Бәлки шуңа күрәдер тәнкыйтен казан татарлары арасында иҗек методына нигез салучы булып саналган Һ. Максудиның «Мөгаллим әүвәл» әлифбасыннан башлый. Бу әлифба 1892 елдан 1917 елга кадәр 1 миллион 200 мең данә тираж белән 31 тапкыр басылып чыга [9, 115 б.]. Г. Әхмәров фикеренчә, «соң заманда чыккан әлифбаларның күбесе «Мөгаллим әүвәл»дән күчереп язылган». Һ. Максуди әлифбасын да ул «мәгънәсез» сүзләр, «зәвыксыз» җөмләләр, төрки сүзләрдә кулланылмаганга төшеп калган гарәп хәрефләр өчен тәнкыйтьли. «Максудиның ысулы педагогия тарихында мәгълүм яңа ысулларның берсенә дә охшамаган», – дигән фикергә килә автор. Ахырдан «Максудиның үзенә махсус бер имласы булганлыктан әлифбасы да шуның кагыйдәсенчә язылган», – дип нәтиҗә ясый. Шулай ук китапны яхшы сыйфаты һәм арзанлыгы өчен мактый [3, 4–8 б.]

Тәнкыйтче Х. Зәбири, Ш. Таһири, Г. Мөслимов һ.б авторларны да читләп үтми. Ш. Таһири әлифбасы [18] педагогик нормаларга туры килә дип саный [3, 55 б.] Автор фикеренчә, Г. Мөслимовның әлифбасы [15] Һ. Максудиның «Мөгаллим әүвәл»е һәм Г. Барудиның «Сәвад ханы» [8] материалларыннан «чүпләп» язылган «өченче китап». Ягъни бу плагиат [3, 33 б.]. Х. Зәбирине [11], мәсәлән, сүзләрне мишәрчә язуда гаепли. Г. Әхмәров үзе дә 1910 елда басылып чыккан «Төрки әлифбасында» «җ» хәрефен еш куллана. Мәсәлән, «җылак бала», «җырак базар», «кар җава» һ.б. [6, 21 б.]. Татар теленең төгәл грамматик нормалары кабул ителмәгән чор өчен бу гаеп түгел. Чынлыкта исә бу әлифбалардагы сүзләрнең язылышы күбрәк халык сөйләм теленә туры килә. Шулай ук Х. Зәбири дә, башка авторлар кебек, «Мөгаллим әүвәл»не үрнәк итеп алган, дип саный Г. Әхмәров [3, 19 б.]. «Зәбиринең тәртибе Максуди тәртибенә охшашлы, әлифбасының күп урыннары «Мөгаллим әүвәлдән» күчереп язылган кеби күренәдер. Сүрәтләр ачык түгел «хәтта танырлыкта түгел», – дип тә өсти автор [3, 28 б.]. Бу тәнкыйт дөрескә туры килә. Беренче рәсемле әлифбаның авторы билгеле түгел. Татар педагогикасын яңа форматка күтәрүче нәкъ Х. Зәбири булырга да бик мөмкин.

Рәсемле әлифбалар 1905 елгы инкыйлабтан соң гына басыла башлый һәм әлифбаларның сыйфаты бик начар була. Дәреслекләрдә рәсемнәр урнаштыру татар педагоглары арасында шау-шу, бәхәс тудыра. Бу тема 1905 елгы инкыйлабка кадәр үк күтәрелгән була. Берәүләр, «рәсем балага әйберне танырга ярдәм итә», – дип фикер йөртсәләр, икенчеләре исә «китаптагы рәсемнәр баланың игътибарын читкә тарта», – дип рәсем урнаштыруга каршы булалар. Өченчеләре, «әйбернең үзен күреп яки аның моделен күрсәтеп сөйләү мөмкинлеге булганда, рәсемне китапка кертүдән һичбер файда юк», – дип саныйлар [12, 49–51 б.]. Г. Әхмәров, мәсәлән, Х. Зәбири әлифбасында урнаштырылган гармун сурәтен тәнкыйтли. Аның фикеренчә, татар халкы бу уен коралын исерекләр кулында һәм трактирларда күбрәк күргәнгә, музыканы сөйсә дә, дәреслек китапларында күрергә әзер түгел [3, 15–29 б.]. Мөгаллимнәр арасында бу тема буенча уртак фикер булмаса да, рәсемле әлифбалар саны елдан ел арта.

Билгеле, татар педагоглары Г. Әхмәровның бу методик кулланмасын игътибарсыз калдырмыйлар. Матбугат битләрендә рецензияләрдә басылып чыга. М. Мөштәриев [16], М. Корбангалиев аңа уңай бәя бирәләр [13]. 1910 елда Г. Әхмәров үзе дә әлифба бастыра. «Татар» этнонимының килеп чыгышы һәм киләчәге буенча дискуссияләр барган елларда ул аны «Татар әлифбасы» дип түгел, ә «Төрки әлифба» дип атый. «Йолдыз» газетасында аноним тәнкыйть тә басылып чыга. Автор Г. Әхмәровны «барлык әлифбаларны себереп түгүче», – дип атый һәм бу әлифбаны бик күтәп алуы турында да яза. Шулай ук әлифба авторын кул астында булган 10 әлифбадагы сүзләрне, җөмләләрне «хәзер материалны куллануда» гаепли. Тәнкыйтьче «кырык беренче әлифба» дөньяга килде дип яза [19]. Мәкалә бик «усал» язылган. Анонимның исемен Г. Әхмәров үзе ача. Шул ук

«Йолдыз» газетасында ул тәнкыйтькә каршы җавабын бастыра. «Аңлашылдыгына күрә – аны Һади әфәнде үзе булырга кирәк», – дигән фикергә килә мөгаллим. Ысул маддияне, яисә иҗек методын, «XVIII гасырныкы» дип атый. Ни өчен әлифба язарга уйлаганын аңлата. Мәктәпләрдәге күп кенә мөгаллимнәр «Мөгаллим әүвәл» буенча мәктәпләрдә «ысул саутия» (аваз методы) укыталар, шуңа күрә «кырык беренче әлифба» кирәк булды дип аңлатма бирә [7]. Ике бөек шәхеснең бәхәсләшүен күрү бер яктан кызык, икенче яктан аяныч. Алар икесе дә татар педагогикасы тарихында тирән эз калдырган кешеләр.

Хәзерге заман күзлегеннән чыгып караганда, һәр әлифба үзенчәлекле тарихи чыганак. Безнең максат кайсы әлифба әйбәтрәк икәнен ачыклау түгел, ә шул уку әсбаплары аша авторларның балаларда нинди әхлакый сыйфатлар тәрбияләргә омтылганнарын аңларга тырышу. Барлык әлифба авторлары беренче урынга дини, милли, әхлакый тәрбияне куйган. Г. Әхмәровның әлифбасы да шул принципларга нигезләнеп төзелгән. Аның фикеренчә, кечкенә балалар өчен сүзләр, җөмләләр укырга аңлаешлы, җиңел булырга, текстлар зәвыклы, тәрбия максатыннан чыгып язылырга тиеш [4]. Татар педагоглары өчен әхлакый тәрбия һәрвакыт беренче урында торган. Бу «Төрки әлифба» текстларында да чагыла: «Бер карт кеше картлыгыннан бөкрәеп йөргәндә, бер яшь егет көлеп: «Бабай ни югалды? Ни карап йөрисен? дигән. Карт: «Әй, углым яшьлегемне җуйдым. Шуны карап барам» дигән». Нәтиҗә: «Карт кешедән көлмә, син дә шулай картаерсың» [6, 31 б.] Текстлар аша балаларга төп әхлакый нормаларны аңлаешлы итеп җиткерергә тырышканнар. Мәсәлән, «Төрки әлифба»да көндәлек тормышта кирәкле төп тәрбия нормалары гади җөмләләрдәдә чагыла:»Тугры сүзле кешенең кадере артык була»; «Аз сөйлә, күп тыңла»; «Ялганчылык белән исеме чыккан кешегә ни кадәр тугры сөйләсә дә ышанмыйлар»[6, 39 б.] һ.б. Г. Әхмәров, шул ук Һ. Максудидан аермалы буларак, ислам дине белән бәйле текстларны әлифбага кертмәгән. Ләкин шәригать кануннарына нигезләнеп язылганнары да аз түгел. Шәригать мөселманнарны түзем булырга, иң беренче нәфесне тыярга өнди. «Бер кеше улына әйткән: «Әй, углым күп ашама, артык ашау адәмне сырхау итә» дип. Улы: «Ачлык кешене үтерә, фәлән кеше ачка үлгән, диләр. Күп ашап үлде дигәнне ишеткәнем юк», – дигәч. Атасы: «Юк, углым, үлчәү белән ашарга кирәк, күп ашау үтермәсә дә – күп яхшылык та күрсәтмәс», – дигән [6, 41 б.]

Һ. Максудиның әлифбасы Г. Әхмәровныкыннан нык аерылып тора. Ул дәреслеккә ислам дине нигезләрен яктырткан текстлар гына түгел, үлем темасын да кертә. Беренче мәртәбә бу тема И. Гаспарлы әлифбасында яңгырый. Һ. Максуди кешенең үлгәннән соң терелүен тасвирлый: «Бервакыт бу дөнья бөтенләй бетәчәк. Ул вакытта дөньядагы кешеләр, хәйваннар – һәрберсе үлеп бетәчәкдер. Шуннан соң үлгән кешеләр һәрберсе яңадан тереләчәкдер. Шул көнне кыямәт көне диләр. Кыямәт көнендә һәрбер кешенең дөньяда кылган эшләре тикшереләчәктер. Изге гамәлле, яхшы кешеләр оҗмахка керәчәктер. Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызны изге вә яхшы

кешеләрдән кылса иде...» [14, 56 б.]. Хәзер мондый текстны дәреслектә күрү бик сәер булып тоела, ә ул чорда үлем турындагы өйрәтмәләр татар балаларының белем һәм тәрбия бирү системасына элек-электән кергән. Кечкенә балаларның психикасына авыр тәэсир иткәндер, мөгаен.

Укуның кирәклеге, белемле кешегә киләчәктә күп мөмкинлекләр ачылуын Г. Әхмәров шулай ук текстлар аша аңлата: «Галим кеше акыллы була. Анысы уку белән табылыр». Галим кешенең акылы көндәлек тормышта да күренергә тиеш: «Бер галимнән сораганнар: «Фәлән кеше турысында ни әйтәсең? Аны халык бик яманлап сөйли», – дип. «Мин аны хурлый алмыйм. Аның тышында гаеп күргәнем юк, эчендә ни бардыр, аны ходайдан башка берәү дә белмәс», – дигән [6, 44–45 б.]. Әлифба балаларны тыйнак булырга да өйрәткән: «Берәү имамдан: «Хәзрәт мәчеттә сәгатьне бормак ничек булыр?» – дип сораган. Имам: «Сәгатьне борып бетергәч шарт иттереп ябарсың да, кеше синең сәгатең барын белер», – дигән [6, 47б.]

1917 елгы инкыйлабка кадәр чыккан барлык татар китаплары кебек үк, әлифбалар да "Бисмилла» сүзләре белән башланган. Шунысы кызык, Г. Әхмәровның сакланып калган әлифбаларында бу сүзләр ябыштырылган. Әлбәттә, бу соңрак эшләнгән булырга тиеш. 1920 елларда, мәктәпләрдә уку әсбаблары җитмәү сәбәпле, элек басылган китапларны киң кулланганнар. Беренче әлифба совет чорында 1922 елда гына басылып чыга [17]. Г. Әхмәровның әлифбасында дини текстлар булмау яңа чор мөгаллимнәре өчен аеруча кулай булгандыр, мөгаен.

Башка авторларның әлифбалары белән чагыштырганда «Төрки әлифба»да бай эчтәлекле текстлар, шигырьләр юк. Г. Әхмәров андый максат куймаган да, чөнки, аның фикеренчә, әлифба кечкенә балалар өчен аңлаешлы, гади булырга тиеш. Зәвыклы текстларны ул 1911 елда басылып чыккан «Кыйриәт төрки»дә китерә. Бу әлифбадан соң уку китабы. Мөгаллим фикеренчә, коры вәгазь, ни кадәр озак сөйләсәң дә, балаларга барып җитми. «Яхшы бул, әдәпле бул», – дип күпме генә тукысаң да, бала бу сүзләрне ишетеп кенә яхшы булмый. Ә менә дәреслекләрдәге мәгънәле хикәяләр бала өчен гыйбрәт һәм үрнәк була ала [4]. «Кыйриәт төрки»дән мисал: «Бер шәкернең сүзләре: «Бер вакыт карчык анама кычкырып сүз кайтарган идем. Шундан соң анамның күңеле төшеп бер почмакка барып утырганын күрдем. «Әни ник болай кәефсезләндең ?» – дип сорадым. Анам: «Ай, углым синең үткән хәлләрең хәтердән чыга башлаганга кайгырып утырам. Син минем кулымда вакытта бик йомшак тавышлы идең. Хәзер тавышың йөрәгемә таштан да катырак булып тоела башлады», – дип җавап биргән [5, 2 б.]. Бу сүзләр йөз елдан соң да йөрәккә үтеп керә һәм уйланырга мәҗбүр итә. «Бер хәлфәнең җавабы» тексты балаларга һәм аларның эти-әниләренә белем алуның ни өчен кирәклеген бик гади итеп аңлатып бирә. «Бер саран кеше баласын укыту өчен хәлфәгә китергән. Бу кеше бай булганлыктан, хәлфә укыткан өчен акча сораган. Бай: «Бала укытканга бу кадәр акча бирәләрмени, мин ул акчага бер көтүче яллармын», – дигән. Хәлфә: «Ялласаң бик яхшы итәрсең, ул вакытта синең ике

көтүчең булыр,» – дигән [5, 3 б.]. Ислам кануннары буенча баланы әдәпле итеп тәрбияләү эти кешенең бурычы, ә ярлы, ятим балаларның әхлакый тәрбиясе, киләчәге өчен милләт җаваплы дип санала [2, 135 б.]. Шуңа күрә татар мәктәпләре һәм мәдрәсәләре меценатлар, я булмаса мәхәллә акчасына ачылган. Бу уку йортларында финанс белән бәйле проблемалар да күп булган. Мәсәлән, яңа ачылган җәдид мәдрәсәләрендә укытучыларның хезмәт хаклары кайвакыт 20 сумга да җитмәгән. Шул чор кешеләренең истәлекләреннән күренгәнчә, бу эш хакы «урам себерүченекеннән» дә кимрәк булган [2, 145–146 б.]. Ләкин татар мөгаллимнәре барлык балаларга да бердәм белем биргәннәр. Мәктәптә укыган баласы өчен гаилә матди хәленә карап акча яисә азык-төлек белән түләгән. Мәсәлән, Г. Тукай бала чагы турында сөйләгәндә, Кырлайда аны тәрбиягә алган әнисенең «укыган өчен, ике бөтен икмәк һәм нибары берме, әллә икеме тиен акча» бирүен әйтә [20, 330 б.]. Хәзерге әлифба, уку китаплары авторлары халкыбызның милли педагогик мирасына мөрәҗәгать итеп, кайбер текстларны үрнәк итеп алсалар, балаларга әхлакый тәрбия бирү юлында зур адым булыр иде.

Укытуның яңа ысулына нигезләнгән татар әлифбалары тарихыбызда үзенчәлекле бер күренеш. Бер яктан, әлифба авторлары һәм төзүчеләре – бу уку китапларына дөньявилыкны кертергә тырышкан, балаларны «аңлаешлы» телдә укытуны яклап чыккан кешеләр. Икенче яктан, әлеге дәреслекләр һәм аларның авторлары – мөселман мөхите җимешләре, шуңа күрә алар диннән башка яши алмаганнар. Татар әлифбасына бу чорда белем бирү бурычы гына түгел, ә мәдәни-агарту миссиясе дә йөкләнгән була. Иң әһәмиятлесе – бу әлифбалар балаларны ана телендә укырга һәм язарга өйрәткән. Г. Әхмәров һәм Һ. Максуди әлифбаларында бу тенденцияләр аеруча яхшы чагыла. Алар икесе дә дәреслекләр төзү методикасына, татар педагогикасының үсешенә зур өлеш керткән шәхесләр.

## ӘДӘБИЯТ

1. Сальникова А.А., Галиуллина Д.М. Татарская «Алифба». Национальный букварь в мультикультурном пространстве (конец XIX – XX вв.) М.: НПБ им. К.Д. Ушинского, 2014. 260 б.
2. Школьный вопрос в русском мусульманстве // Мир ислама. 1913. Т. 2. Вып. 3. С. 131–151.
3. Әхмәров Г. Әлифба китапларына тәнкыйть. Казан: Үрнәк, 1909. 64 б.
4. Әхмәров Г. Кыйриәт төрки. 1 нче кисем. Казан: Лито-типография И.Н. Харитонова, 1911. 40 б.
5. Әхмәров Г. Кыйриәт төрки. 2 нче кисем. Казан: Лито-типография И.Н. Харитонова, 1911. 64 б.
6. Әхмәров Г. Төрки әлифба. Ысул саутия үзара тәртип ителмеш. Казан: Лито-типография И.Н. Харитонова, 1910. 51 б.
7. Әхмәровның җавабы // Йолдыз. 1910. 11 ноябрь.
8. Баруди Г. Сәвад хан. Казан: б.у.ю., 1892. 24 б.

9. Вәлиуллин Р.Н. Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен гуманитар фәннәр буенча дәреслекләр (XIX йөз азагы – XX йөз башы). Казан: Фән, 2004. 219 б.
10. Гайнетдин Әхмәров: тарихи-документаль җыентык. Казан: Хәтер, 2000. 384 б.
11. Зәбири Х. Мәктәп балаларына юлдаш, яхүд рәсемле әлифба. Казан: Типо-литог. Импер. универ., 1907. 50 б.
12. Ибраһимов Ф. Белем әлифбадан башлана (татарча уку-язуга өйрәтү методикасы һәм татар әлифбалары тарихы). Казан: Мәгариф, 1994. 255 б.
13. Корбангалиев М.Г. Әхмәров китапларына тәнкыйть // Йолдыз. 1910. 31 октябрь.
14. Максуди Һ. Мөгаллим әүвәл. Ысул мәддия үзара тәртип ителмеш әлифбадыр. Казан: Лито-типог. И.Н. Харитонова, 1903. 80 б.
15. Мөслимов Г. Сабыйларга юл башы. Казан – Уфа: Матбуга Кәримия, 1908. 32 б.
16. Мөштәриев М. Әлифба китапларына тәнкыйть // Бәянелхак. 1909. 17 ноябрь.
17. Татар әлифбасы. Мәктәп балалары өчен. Казан: Тат. соц. совет. җөмһ. дәүләт нәшере., 1922. 63 б.
18. Таһири Ш. Мөкәмәл әлифба. Казан: Лито-типог. И.Н. Харитонова, 1910. 71 б.
19. Төрки әлифба // Йолдыз. 1910. 28 октябрь.
20. Тукай Г. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар һәм чәчмә әсәрләр. Казан: Тат. китап. нәшр., 2003. 480 б.

**Автор турында белешмә:** Галиуллина Диләрә Магъзум кызы – тарих фәннәре кандидаты, ватан тарихы кафедрасы доценты, Халыкара багланышлар институты, Казан федераль университеты (420111, Сул як Булак урамы, 44, Казан, Россия Федерациясе); galiullinadm@mail.ru

## ПРОБЛЕМЫ НРАВСТВЕННОГО ВОСПИТАНИЯ ДЕТЕЙ В БУКВАРЕ Г. АХМАРОВА «ТӨРКИ ӘЛИФБА» («ТЮРКСКИЙ БУКВАРЬ»)

***Д.М. Галиуллина***

*Казанский федеральный университет*
*Казань, Российская Федерация*
*galiullinadm@mail.ru*

В статье рассматривается букварь Г. Ахмарова «*Төрки әлифба*» («Тюркская алифба») как исторический источник по истории татарской педагогической мысли и истории детства. Тексты изучаются и в связи с проблемами нравственного воспитания подрастающего поколения. Также анализируется методическое пособие Г. Ахмарова «*Әлифба китапларына тәнкыйть*» («Критика букварей»). В ней автор подвергает критике буквари Х. Забири, Ш. Тахири, Г. Муслимова и др. Начинает критику с самого распространенного в школах букваря «*Мөгаллим әүвәл*» Х. Максуди. Поэтому в работе этому букварю уделено особое внимание. В 1910 г.

Г. Ахмаров опубликовал свой букварь «*Төрки әлифба*». В связи с этим между Х. Максуди и Г. Ахмаровым разгорелась дискуссия на страницах газеты «Йолдыз», которая раскрывает не только взаимоотношения этих выдающихся личностей, но и их отношение к вопросам школьного образования и вопросам нравственного воспитания. Также проведен сравнительный анализ текстов двух букварей. Содержание текстов отличается. Г. Ахмаров отдавал предпочтение небольшим текстам и его букварь более светский, чем «*Мөгаллим әүвәл*». В букваре Х. Максуди много ярких, интересных текстов, в том числе и религиозного характера. Несмотря на различия, авторы букварей ставили перед собой одну цель – научить детей читать и писать на родном языке. Действительно, цель была достигнута. Этими букварями в татарских школах пользовались до октябрьской революции 1917 г.

**Ключевые слова:** «Төрки әлифба», «Йолдыз», «Мөгаллим әүвәл», культура, история, источник, джадидизм, нравственность, воспитание.

**Для цитирования:** Галиуллина Д.М. Г. Әхмәровның «Төрки әлифбасы» битләрендә балаларга әхлакый тәрбия бирү мәсьәләләре // Историческая этнология. 2019. Т. 4, № 2. С. 274–283. DOI: 10.22378/he.2019-4-2.274-283

**Сведения об авторе:** Галиуллина Диляра Магзумовна – кандидат исторических наук, доцент кафедры отечественной истории Института международных отношений, Казанский федеральный университет (420111, ул. Лево-Булачная, 44, Казань, Российская Федерация); galiullinadm@mail.ru

## PROBLEMS OF MORAL EDUCATION OF CHILDREN IN G. AKHMAROV'S PRIMER "TORKI ALIFBA" ("TURKIC PRIMER")

***D.M. Galiullina***

*Kazan Federal University*
*Kazan, Russian Federation*
*galiullinadm@mail.ru*

The article discusses G. Akhmarov's primer "Torki alifba" ("Turkic Alifba") as a historical source on the history of Tatar pedagogical thought and the history of childhood. The texts are also studied in relation to the problems of moral education of the adolescent generation. It also examines G. Akhmarov's methodological guide "Lifb of cataplana tncy" ("Criticism of ABC books"). In tht work the author criticizes the primers of H. Zabiri, Sh. Tahiri, G. Muslimov, etc. However, criticism begins with H. Maksudi's primer "Mogallim auval", whoch was most commonly used in schools. Therefore, particular attention is paid to this primer in the work. In 1910, G. Akhmarov published the primer "Torki alifba". In this regard, a discussion broke out between H. Maksudi and G. Akhmarov on the pages of the newspaper "Yoldyz", which reveals not only the relationship of these outstanding personalities, but also their attitude to school education and moral education. Also, a comparative analysis of the texts of two

alphabets has been conducted. The content of the texts is different. G. Ahmarov prefers texts of small volume and his primer is of more secular nature than “Mallim VL”. In the primer H. Maksudi has many bright, interesting texts, including religious ones. Despite the differences, the authors of the ABC-books set themselves one goal – to teach children to read and write in their native language. Indeed, the goal was achieved; these primers were used in schools until the revolution of 1917.

**Keywords:** “Torki Alifba”, “Yoldyz”, “Mogallim auval”, culture, history, source, jadidism, morality, education.

**For citation:** Galiullina D.M. Problems of moral education of children in G. Akhmarov’s primer “Torki Alifba” (“Turkic primer”). Istoricheskaya etnologiya – Historical Ethnology, 2019, vol. 4, no. 2, pp. 274–283. DOI: 10.22378/he.2019-4-2.274-283

## REFERENCES

1. Salnikova A.A., Galiullina D.M.. *Tatarskaya Alifba. Nacional’nyj bukvar’ v multikul’turnom prostranstve (konets XIX – XX vv.)* [Tatar primer. National ABC-book in the multicultural space )late 19th–20th centuries]. Moscow, K.D. Ushinsky Research and Education Library Publ., 2014. 260 p. (In Russian)

2. Shkol’nyj vopros v russkom musul’manstve [The issue of schools in the Russian Muslim society]. *Mir Islama – The World of Islam*, 1913, v.2, issue. 3, pp. 131–151. (In Russian)

3. Akhmarov G. *Alifba kitaplaryna tenkyjt’* [Criticism of primer books].Kazan, Urnek Publ., 1909. 64 p. (In Tatar)

4. Akhmarov G. *Kyyeret Törki. 1 kisem* [Reading in Turkic. Part 1]. Kazan, Kharitonov Printing House, 1911. 40 p. (In Tatar)

5. Akhmarov G. *Kyyeret Törki. 2 kisem* [Reading in Turkic. Part 2]. Kazan, Kharitonov Printing House, 1911. 64 p. (In Tatar)

6. Akhmarov G. T *Törki alifba. Ysul sautiya üzara tartip itelmesh* [Compiled based on the sound method]. Kazan, Kharitonov Printing House, 1910. 51 p. (In Tatar)

7. Akhmarovnyn jevaby [Akhmarov’s reply]. *Yoldyz – Star*, 1910 November 11. (In Tatar)

8. Barudi G, *Sevad khan* [Sevad khan]. Kazan,,1892. 24 p. (In Tatar)

9. Valiullin R.N. *Tatar maktap-madrasalare öchen gumanitar fannar buencha daresleklar (XIX jöz azagy – XX jöz bashy)* [Textbooks for the humanities for Tatar school-madrasas (late 19th – early 20th centuries)]. Kazan, Fen Publ., 2004. 219 p. (In Tatar)

10. *Gajnetdin Akhmarov: tarikhi-dokumental’ jyientyk* [Gajnetdin Akhmarov: A historical-documentary collection]. Kazan, Khater Publ., 2000. 384 p. (In Tatar)

11. Zabiri H. *Maktap balalaryna yuldash, yahud rasemle alifba* [A companion for schoolchildren, An ABC-book with pictures]. Kazan, Printing House of Imperial Univ., 1907. 50 p. (In Tatar)

12. Ibragimov F. *Belem alifbadan bashlana (tatarcha uku-yazuga öjretü metodikasy hem tatar alfbalary tarihy)* [Knowledge starts from an ABC-book (the histo-

ry of teaching reading and writing in Tatar and Tatar ABC-books]. Kazan, Magarif Publ., 1994. 255 p. (In Tatar)

13. Korbangaliev M.G. *Akhmarov kitaplaryna tankyjt'* [Criticism of Akhmarov's books]. *Yoldyz – Star*, 1910, October 31.

14. Maksudi H. *Mogallima Aüval. Ysul maddiya üzra tartip itelmesh alifbadyr* [Primer compiled based on the syllable method]. Kazan, Kharitonov Printing House, 1903. 80 p. (In Tatar)

15. Muslimov G. *Sabyjlarga yul bashy* [The beginning of the road for toddlers]. Kazan – Ufa, Matbuga Karimiya Publ., 1908. 32 p. (In Tatar)

16. Moshtariev M. *Alifba kitaplaryna tankyjt'* [Criticism of primer books]. *Bayanelhak* . 1909, November 17. (In Tatar)

17. Tatar *alifbasy. Maktap balalary öchen* [Tatar ABC-book. For schoolchildren]. Kazan, Tatar Social Soviet Rep. Publ. , 1922. 63 p. (In Tatar)

18. Tahiri Sh. *Mökemel alifba* [Improved primer]. Kazan, Kharitonov Printing House, 1910. 71 p. (In Tatar)

19. Törki Alifba [Turkic Primer]. *Yoldyz – Star*, 1910 October 28. (In Tatar)

20. Tukay G,. *Sajlanma asarlar: shigyrlar, poemalar ham chachma asarlar* [Selected works: poems, narrative poems and prose]. Kazan, Tatar Book Publ. House, 2003. 480 p. (In Tatar)

**About the author:** Dilyara M. Galiullina is a Candidate of Sciense (History), Associate Professor of the Department of Russian History, Institute of International Relations, Kazan Federal University (44, Levobulachnaya St., Kazan 420111, Russian Federation); galiullinadm@mail.ru